Җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында
Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 24, 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2007 елның 24 мартындагы 66 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында Җәмәгать тыңлауларын үткәрү турында» Нигезләмә нигезендә, кеше яшәешнең уңай шартларына, җир участокларына һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында Балтач муниципаль район башлыгы КАРАР БИРӘ:

1. Норма авыл җирлеге халкы катнашында «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Норма, Кариле авыл гражданнары өчен «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын ачык тыңлаулар 2019 елның 3нче август сәгать 8:00 дән 8:30га кадәр Норма мәдәният йортында (Татарстан Республикасы, Балтач районы, Норма авылы, Казан урамы, 11нче йорт) уздырырга.

3. Татарстан Республикасы, Балтач районы, Кили авылы, Г. Тукай урамы, 33/3 йорт адресы буенча урнашкан Кили авыл клубында Кили, Пүскән, Нормабаш авыллары гражданнары өчен «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын ачык тыңлаулар үткәрергә.

4. Балтач муниципаль районының «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын әзерләү буенча комиссияга (алга таба - Комиссия) ачык тыңлаулар үткәрергә .

5. Комиссиягә «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планының демонстрацион материалларының күргәзмә-экспозициясен оештырырга, гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

6. Генераль план проекты буенча гражданнардан тәкъдимнәр әлеге карар басылып чыкканнан соң бер ай дәвамында Норма авыл җирлеге җитәкчесе урынбасары тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Норма авылы, М. Җәлил урамы, 2а йорт.

7. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatar.ru һәм Норма авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р.Нутфуллин